ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.02.2019 г. Заинск № 66

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 6 маендагы 1007 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы , бюджет акчаларын нәтиҗәле сарыф итү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 нче елның 6 нчы маендагы 1007 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына кушымта (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 апрелендәге 776 номерлы һәм 2017 елның 17 октябрендәге 1875 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 3 бүлекнең 3.2 пункты "Укучыларга туклануны бирү тәртибе»нә түбәндәге эчтәлекле пунктчаларны өстәргә:
«инвалид- балалар»;
1.2. 3 бүлекнең 3.2.1 пунктына «Укучыларга туклану бирү тәртибе» 3.2.1.3 пунктчаларына киләсе эчтәлекне өстәргә: «3.2.1.3. Инвалид бала булган гаиләдән:
- ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы);
- социаль педагог, сыйныф җитәкчесе, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары составындагы комиссия тарафыннан торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты;
- гаилә составы турында белешмә;
- инвалидлык турында белешмә»;
2. Оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Зәй

муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга;

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Н.А. Алчина
7-08-07